**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлкимуниципаль районы**
**Ташбилге авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Адресы: 422870, ТР, Әлки районы, Ташбилгеавылы, Үзәкурамы,32 йорт , тел./факс 8(84346) 72-6-46

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет Тяжбердинского сельского поселения**
**Алькеевскогомуниципального района**
Адрес: 422870, РТ, Алькеевский район, с. Тяжбердино, ул.Центральная, д.32, тел./факс 8(84346) 72-6-46

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Ташбилге авылы** **КАРАР**

**25.01. 2021 ел** **3№**

## Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы "Җирләү һәм җирләү эше турында" 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы "Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" 196 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Ташбилге авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымта нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Ташбилге авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 20 мартындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Ташбилге авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 6 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru.порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Ташбилге авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Р.Ф.Әхмәдиев

Ташбилге авыл җирлеге башкарма комитетының 2022елның 25 гыйнварындагы 3№ карарына 1 нче кушымта

Ташбилге авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б № | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 4011,67 |
| 3. | Мәрхүмнең мәетен (калдыгын) зиратка китерү | 1448,65 |
| 4. | Җирләү (каберне казу һәм күмү) | 1504,36 |
| | Барлыгы: | 6964,68 |

Ташбилге авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022елның 25 гыйнварындагы 3 № карарына 2 нче кушымта

## Ташбилге авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б № | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Кәфенләү | 1337,91 |
| 3. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2668,19 |
| 4. | Мәрхүмнең мәетен (калдыгын) зиратка китерү | 1448,65 |
| 5. | Җирләү (каберне казу һәм күмү) | 1509,93 |
| | Барлыгы: | 6964,68 |